МИНИСТЕРСТВО
ЗДРАВООХРАНЕНИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.02.2024 г. Казань № 400

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 19.08.2022 ел № 2261 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

Кушымта итеп бирелүче, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 19.08.2022 ел №2261 боерыгына кертелә торган үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 14.11.2022 № 2986 боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән).

Министр вазыйфаларын башкаручы Ә.Р.Абашев

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
20*24* елның «*19*» *02* №*400*
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 19.08.2022 ел № 2261 боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1. Преамбула өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары » сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга.

2. Күрсәтелгән боерык белән расланган, Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентында:

2.6 пунктның 2.6.1 пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) оешманың җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән (мөһере булган очракта) расланган оештыру документларының күчермәләре.»;

Административ регламентына Кушымта №1дә «чит ил агенты функциясен үтәүче коммерциячел булмаган оешма түгел,» сүзләрен төшереп калдырырга;

Күрсәтелгән административ регламентка кушымтаны (белешмә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына Кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 2227098 | minzdrav@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 2227091 | minzdrav@tatar.ru |
| Идарә башлыгы | 2227028 | minzdrav@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | 2227064 | minzdrav@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе | 2647784 | Raushan.Zaripov@tatar.ru |

».